ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктына «гамәлгә ашыручы оешма» сүзләреннән соң «(алга таба шулай ук – проектны гамәлгә ашыра торган оешма)» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гавами проектлау инициативасын формалаштырганда капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкару хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган гомуми таләпләргә туры килә торган декларация рәвешен раслау;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) инвестиция проектын карау һәм дәүләт (муниципаль) ярдәме чараларын куллану максатларында инвестиция проектының Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты акчаларын нәтиҗәле куллану критерийларына туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында аңа бәяләмә әзерләү. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, проектны гамәлгә ашыручы оешмадан инвестиция проектын карау турында гариза кергән көннән алып чираттагы эш көненнән дә соңга калмыйча, мондый гариза керү турында социаль-

икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә хәбәр итә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, проектны гамәлгә ашыручы оешмадан шундый гариза кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, инвестиция проектын карый һәм аның нәтиҗәләре турында проектны гамәлгә ашыручы оешмага һәм социаль-икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына хәбәр итә. Күрсәтелгән хәбәрнамәләргә инвестиция проектын карау нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәнең күчермәсе кушымта итеп беркетелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы билгеләнгән срокларда бәяләмәне проектны гамәлгә ашыручы оешмага һәм социаль-икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына җибәрмәсә, йә күрсәтелгән хәбәрнамәгә инвестиция проектына бәяләмәнең күчермәсен кушымта итеп беркетмәсә, инвестиция проекты уңай бәяләмә алган дип санала;»;

3) 6 статьяның 2 өлешендә «социаль-икътисадый» сүзен төшереп калдырырга;

4) 9 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «салымны кайтаруны» сүзләреннән соң «(әгәр капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү Россия Федерациясе белән төзелгән булса)» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт ярдәме чаралары төсле металл (алтын) рудалары чыгару өлкәсендә капитал салулары күләме кимендә 300 миллиард сум булган проектны гамәлгә ашыручы һәм региональ инвестиция проектларында катнашучылар реестрына кертелгән, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү төзегән оешмага бирелми.»;

в) 5 өлештә:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимияте органының салым контролен үткәргән вакытта проектны гамәлгә ашыручы оешманың әлеге статьяның 1 өлешендә каралган фактта тотылган чыгымнар күләмен бозып күрсәтү фактлары ачыкланмау (ачыклану) турында, шулай ук проектны гамәлгә ашыручы оешмага карата әлеге статьяның 1 өлешендә каралган фактта тотылган чыгымнар күләмен

билгеләүнең дөреслеге мәсьәләсе буенча үткәрелгән салым мониторингы кысаларында чыгарылган үтәлмәгән дәлилләнгән фикерләрнең булмавы (булуы) хакында бәяләмәсе бирелгән булса;»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) проектны гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителсә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 64-ТРЗ